МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

16.08.2019 г.Казань № 624

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 9 сентяберендә 5783 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2019 елның 20 июнендәге 484 номерлы боерыгы керткән үзгәрешләре белән) белән расланган Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2019 елның 16
августындагы 624 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән раслангын Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2018 елның 31 августындагы 825 номерлы боерыгы белән раслангын Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

2.13 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.4 пунктның 3.4.2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгече учреждениегә (вәкаләтле оешмага) соратып алына торган мәгълүматларны бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар белешмәләр белән эш итүче дәүләт органына, җирле үзидарә органына, дәүләт органына яисә җирле үзидарә органына караган оешмага гарызнамә кергән көннән алып ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Тапшырылган мәгълүматлар административ процедураның нәтиҗәсе булып тора.»;

3.5 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар алдагы процедуралар – тәмамланган көннән алып бер эш көне эчендә, ә ашыгыч социаль хезмәтләр күрсәтү турындагы гаризаны караган очракта кичекмәстән гамәлгә ашырыла.»;

3.6 пунктның 3.6.1 пунктчасындагы өченче абзацта «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта:

3.7.1 пунктчаның бишенче абзацында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.2 пунктчаның икенче абзацында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.7.3 пунктчаның икенче абзацында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.9 пунктта:

3.9.4 пунктчаның икенче абзацында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

3.9.5 пунктчаның өченче абзацында «мизгелдән башлап» сүзләрен «көннән башлап» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 8 нче кушымтаның «Гражданинны билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә социаль хезмәт күрсәтүнең стационар социаль хезмәтләр күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районында (шәһәр округында) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы территориаль органына тапшырылырга тиешле документлар исемлеге» дигән таблицаның 1 пунктының 1.2 пунктчасында «документларны биргән вакыттан башлап вакыты чикләнмичә» сүзләрен «законнарга туры китереп» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 13 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 3 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «3. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 14 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 15 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 16 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 17 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$1^1$. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча | законнар нигезендә»; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | бүлекчәсе | |

Регламентка 18 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «5. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 19 нчы кушымтага түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 20 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә::

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$1^1$. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 21 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пунктча өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «$3^1$. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 22 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «4. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 23 нче кушымтага түбәндәге эчтәлекле 2 пункт өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «2. | Хосусый шәхси счетның иминият номеры | ДУ – Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе | законнар нигезендә»; |

Регламентка 24 нчы кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 24 нче кушымта

Гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ итеп тану һәм социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасын төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең блок-схемасы

мөрәҗәгать итүче

↓

Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районындагы (шәһәр округындагы) социаль яклау идарәсенә (бүлегенә) (алга таба – Министрлыкның территориаль органы); әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә территориаль беркетелгән балалар һәм яшүсмерләр өчен социаль приютка, билгеле бер яшәү урыны һәм шөгыльләре булмаган затларны социаль яраклаштыру үзәгенә (алга таба – вәкаләтле оешма) мөрәҗәгать итү

↓

Социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаны (мөрәҗәгатьне) һәм тапшырылган документларны таләпләргә туры килү-килмәве буенча карау әлеге регламентның 2.5 һәм 2.8 пунктлары

| ↓ | ↓ |
|---|---|
| Документлар таләпләргә туры килә | Документлар таләпләргә туры килми |
| ↓ | ↓ |
| Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече:<br>- социаль хезмәтләр күрсәтү турында гаризаларны теркәү журналында (алга таба - гаризаларны теркәү журналы) терки. Гаризаларны теркәүгә алу журналының рәвеше әлеге Регламентның 25 нче кушымтасында күрсәтелде;<br>– әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә документларны кабул итү турында теркәү журналында тамга ясый; | Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), бүтән гражданнарга, дәүләт органарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) гаризаны һәм документларны кайтарып бирү сәбәпләрен күрсәтеп, теркәмичә кайтарып бирә |

| | |
|---|---|
| – гаризаны теркәү датасы турында мөрәҗәгать итүчегә, кергән номерын теркәп, язунамә тапшыра (җибәрә);<br>- Министрлыкның территориаль органы белгече гаризаны һәм тапшырылган документларны Учреждениегә тапшыра. | |

↓

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече дәүләт хезмәтләре яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы органнарга (оешмаларга) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында гарызнамәләр җибәрә

↓

Ведомствоара хезмәттәшлек органы белгече учреждениегә (вәкаләтле оешмага) соратып алына торган мәгълүматларны бирә

↓

Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тарафыннан үз инициативасы нигезендә тапшырылган һәм (яки) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынган (тапшырылган) документларны (белешмәләрне) әлеге Регламентның 2.9 пункты таләпләренә туры килү-килмәве буенча карый: гражданинның яшәеш шартларын начарайта яки начарайтырга мөмкин булган шартлар булуын (булмавын) билгели, гражданинны социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип тану турында (танудан баш тарту турында) карар проекты (алга таба – карар), мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданиннар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәр проекты әзерли һәм имза кую өчен Министрлыкның территориаль органы җитәкчесенә (вәкаләтле оешма җитәкчесенә) җибәрә

↓

Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешманың директоры) карар проектын һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый

| |
|---|
| берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәр проектын имзалый |

↓

| |
|---|
| Министрлыкның территориаль органы белгече карарны һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәрне җибәрә |

↓

| |
|---|
| Министрлыкның территориаль органы (вәкаләтле оешма) белгече карарны һәм мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) адресына хәбәрне җибәрә |

↓

| |
|---|
| Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече гражданинның социаль хезмәтләр күрсәтелүгә хосусый ихтыяҗын билгели, ике нөсхәдә социаль хезмәтләр күрсәтүнең хосусый программасы проектын (алга таба – СХКХП) төзи һәм раслау өчен Министрлыкның территориаль органына (вәкаләтле оешма директорына) җибәрә |

↓

| |
|---|
| Министрлыкның территориаль органы җитәкчесе (вәкаләтле оешма директоры) СХКХП карый һәм имзалый, аны дәүләт хезмәтен алучыга (законлы вәкилгә), бүтән гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тапшыруны оештыру өчен Учреждение (вәкаләтле оешма) белгеченә җибәрә |

↓

| |
|---|
| Учреждение (вәкаләтле оешма) белгече мөрәҗәгать итүчене (законлы вәкилне), бүтән гражданнарны, дәүләт органнарын, җирле үзидарә органнарын, иҗтимагый берләшмәләрне (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) СХКХП белән таныштыра, биредә мөрәҗәгать итүче (законлы вәкил), бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә |

органнары, иҗтимагый берләшмәләр (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) үзенең имзасын куя, бер нөсхәне мөрәҗәгать итүчегә (законлы вәкилгә), бүтән гражданнарга, дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, иҗтимагый берләшмәләргә (гражданин мәнфәгатьләрендә бүтән гражданнар, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр мөрәҗәгать иткән очракларда) тапшыра. Учреждение белгече СХКХП икенче нөсхәсен Министрлыкның территориаль органына җибәрә, вәкаләтле оешма белгече – социаль хезмәтләр алучының шәхси эшенә теген куя».